Республика Татарстан
Совет Новоимянского сельского
поселения Сармановского
муниципального района
ул. Гагарина, д. 39, с.Кутемели, 423355.
Телефон: (85559) 4-63-36, факс: 4-63-36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл жирлеге Советы
Гагарин урамы, 39 йорт, Күтәмәле авылы,
423355. Телефон: (85559) 4-63-36, факс: 4-63-36

ОКПО 93068373 ОГРН 1031604000174 ИНН/КПП 1636001308/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 ноябрь 2023 ел Күтәмәле авылы № 5

Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылында 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләп кую

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгы

Карар:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Яңа Имән авылы Муса Җәлил урамы, 25А йорт адресы буенча урнашкан Яңа Имән авылы мәдәният йорты бинасында 2023 нче елның 22 ноябрендә 13 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Яңа Имән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә

әгъзаларыннан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме?:

1) Яңа Имән авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

2) җәйге чорда территорияне чабу, урып-җыю (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

4) янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

5) Яңа Имән авылында күпләп ял итү урыннарын төзү һәм төзекләндерү (материаллар, сәхнәләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

6) Яңа Имән авылында «Махмурахман»,Зиннур» чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» « ЮК».

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Яңа Имән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Гараев